ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.11.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3277**

2023 елга «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында норматив чыгымнарны раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге «Татарстан Республикасында балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләп чыгару тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»» 939 номерлы карары һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга түбәндәгеләрне расларга:

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экологик-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга кушымта итеп бирелгән норматив чыгымнарны;

балаларга өстәмә белем бирүче туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүнең күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтмә коэффициентны 0,65 күләмендә.

2. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган, балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә, балаларга өстәмә белем бирү буенча мәгариф оешмаларын финанслауны;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булу чоры дәвамында хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә яңадан карауны

3. . Әлеге карар 2023 елның 1 январеннән үз көченә керә.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan. ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 28 нче ноябрендәге
3277 нче номерлы карарына карата
кушымта

2023 елга «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә балаларга өстәмә белем бирүче туристлык- туган якны өйрәнү, экологик-биология, хәрби-патриотик, социаль- педагогик, социаль-икътисади, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүче күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашуы | Бер елга 1 укучыга норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм аннан соң килә торган еллары |
| Сәнгати-эстетик | шәһәр җирлеге | 7 851 | 14 539 | 17 447 |
| | авыл җирлеге | 8 251 | 15 280 | 18 336 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 7 750 | 14 351 | 17 222 |
| | авыл җирлеге | 8 150 | 15 093 | 18 111 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 8 155 | 15 101 | 18 121 |
| | авыл җирлеге | 8 555 | 15 842 | 19 011 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Экологик-биология | шәһәр җирлеге | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 7 547 | 13 977 | 16 772 |
| | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 7 547 | 13 977 | 16 772 |
| | авыл җирлеге | 7 948 | 14 718 | 17 661 |
| Табигый- фәнни | шәһәр җирлеге | 7 952 | 14 726 | 17 671 |
| | авыл җирлеге | 8 352 | 15 467 | 18 561 |